# ИЯРТҮЛЕ БӘЙЛӘНЕШ

Татар теле һәм әдәбияты
укытучысы Арсланова З. Җ.

# ИЯРТҮЛЕ БӘЙЛӘНЕШ

- Ачыклаулы мөнәсәбәт *яшел алма*
- Хәбәрлекле мөнәсәбәт *күз җитте*
- Аныклаулы мөнәсәбәт *без, ягъни 7 нче сыйныф укучылары*

# АЧЫКЛАУЛЫ МӨНӘСӘБӘТ

- Китапны уку
- Ефәк яулык
- Әти белән бару
- Быел очрашу
- Күргәч әйтү
- Урманга кадәр бару
- Бишенче сыйныф

# ХӘБӘРЛЕКЛЕ МӨНӘСӘБӘТ

- Көн матур
- Син киләсеңме?
- Мин – укучы
- Алар килделәр
- Китап минеке
- Күз җитте

# АНЫКЛАУЛЫ МӨНӘСӘБӘТ

- Кызлар, бигрәк тә Галия белән Алсу, бу хәлгә бик шатландылар
- Сәвия әнисе яраткан көйне – “Рамай”ны уйный иде.
- Ул атасына охшаган: күп сөйләми, эшли дә эшли.

# ТЕКСТТАН АЧЫКЛАУЛЫ МӨНӘСӘБӘТТӘ БУЛГАН СҮЗЛӘРНЕ ЯЗАРГА

- Күренекле галим, укытучы педагог һәм әдип К. Насыйри татар мәгърифәтчелек хәрәкәте һәм әдәбияты үсешендә зур роль уйнады. Аның ярты гасырга сузыл- ган күптармаклы һәм нәтиҗәле эшчәнлеге халыкка хезмәт итүгә, милләтнең аң- белем дәрәҗәсен күтәрүгә юнәлдерел-гән. Күпчелек халыкка аңлаешлы татар әдәби телен гамәлгә ашыру теләге бе-лән янып-көеп йөрүче бөек шәхес.

# ТЕКСТТАН ХӘБӘРЛЕКЛЕ МӨНӘСӘБӘТТӘ БУЛГАН СҮЗЛӘРНЕ ЯЗАРГА

- Ата, улы Хафизны мәдрәсәдә калдырып, кайтып китте. Чит җирдә ,танымаган кешеләр арасында,Хафиз башта бик ямансулады .Бүре баласы төсле,читтә ятсыныпторган мужик малаен шәкертләр, урап алып ,” сайратырга “керештеләр.
- Атна буе салкын җил исте. Инешләр туңды, уҗым басулары, түгәрәк урман артында диңгездәй җәелеп яткан сазлык туңды.

# ТЕКСТТАН АНЫКЛАУЛЫ МӨНӘСӘБӘТТӘ БУЛГАН СҮЗЛӘРНЕ ЯЗАРГА

- Без, шул тирә малайлары, Галләм абзыйның кайтканын дүрт күз белән көтеп торабыз.
- Түбәндә, үзәндә, соры зәңгәр пар эчендә авыл җәйрәп ята.
- Еракта зәңгәр яшен яктысы – аҗаган кабына.
- Юан имәннең очында ук кызыллы-сарылы чәчәкләр – кызылтүшләр күренгәләп китә.